Хәлим Җәләлов
Корчаңгы тай
һәм Таз малай

**Хәлим Җәләлов**

# Корчаңгы тай һәм Таз малай

*Әкият*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1993

ББК 84(Тат)-4
Җ82

*КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН*

Художнигы *АЛСУ ТИМЕРГАЛИНА*

Җәләлов Хәлим
Җ82 Корчаңгы тай һәм Таз малай: Әкият. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.— 32 бит.
ISBN 5—298—00332—X

Укучыларга яхшы таныш булган бу татар халык әкиятен Хәлим Җәләлов балалар гына түгел, зурлар да яратып укырлык әсәргә әйләндергән. Сыгылмалы, йөгерек, халыкчан теле әкиятне тагын да укылышлы итә.

**Җ $\frac{4803560104—097}{М132(03)—93}$ 122—94** **ББК 84(Тат)-4**

ISBN 5—298—00332—X

© Татарстан китап нәшрияты, 1993

Борын-борын заманда,
Борыны китек команда,
Үгез үрәтник булган,
Песи десятник булган,
Саескан сотник икән,
Бака плотник икән.

Сумала чәер булган,
Кешеләр сәер булган.

Бозга бодай чәчкәннәр,
Суда солы иккәннәр,
Тәртә белән чапканнар,
Дуга белән урганнар.
Парлап тавык җиккәннәр —
Шулай гомер иткәннәр.

Яшәгән, ди, бер кеше,
Авызында өч теше,
Булган аның өч улы,
Өченчесе кычулы.
Шуңа мыскыл иткәннәр,
«Таз» дип кенә йөрткәннәр.

Аталары сау чакта
Иген иккәннәр алар,
Уртача гына тормышта
Гомер иткәннәр алар.
Тамаклары тук булган,
Кайгылары юк булган.

Ел артыннан ел үткән.
Әтиләре картайган.
Егәр беткән, көч киткән,
Карт агач күк муртайган.
Күзләр беткән чекрәеп,
Арка чыккан бөкрәеп.

Әтиләре беркөнне
Әйтә икән боларга:
— Солы сатып алырсыз,
Барыгыз,— дип,— базарга.
Биш поттан ким булмасын,
Җиребез кысыр тормасын.

Малайлары базардан
Алып кайтканнар солы.
Чәчәләр кырга чыгып,
Сиксән сажин җир буе.
«Игеннәр яхшы уңсын,
Бәрәкәт белән булсын!»

Бер атнадан баралар,
Күреп хәйран калалар:

— Чәчкәнгә атна үтте,
Кап-кара җирнең өсте.
Тишелмәгән ич солы,
Ни ашарбыз ел буе?!

Аталары дулаган:
— Җүләрләр, уңмаганнар,
Солыга дигән акчаны
Җуйгансыз, булмаганнар.
Җүнсез булды улларым,
Эшкә ятмый куллары.

Малайлары аклана:
— Чәчкәнбез,— диләр,— сирәк,
Әйбәт тишелсен дисәк,
Куерак чәчәргә кирәк.
Әҗәткә солы алыйк,
Тагын бер чәчеп карыйк.

Тагын алып кайталар
Әҗәткә биш пот солы.
Чәчүлек чиста, коры.
«Уңарбыз без бу юлы.
Үскәч өмә ясарбыз,
Коймак пешереп ашарбыз».

Бер атна вакыт үтә,
Барырга вакыт җитә.
Барсалар — тагын шул хәл,
Кайдан табарга әмәл?

Җирнең өсте кап-кара,
Әрәм булган орлык җәл.

Карт шунда кала шиккә:
— Чара табыйк ничек тә.
Сез акыллы, сез зирәк,
Төнлә сакларга кирәк.
Чиратлашып саклагыз,
Төнлә керфек какмагыз!
Иң беренче нәүбәттә
Олы малай, әлбәттә,
Төнлә сакларга бара,
Ә төн шомлы, кап-кара.
Курку били күңелен,
Коты чыга мескеннең.

Төн буе саклау кая?!
Бераз тора да тая
Аулакта качып ята,
Иртән өенә кайта:
— Китеп-нитеп йөрмәдем,
Бернәрсә дә күрмәдем.

Икенче кич тә җитә,
Уртанчы малай китә.
Төн караңгы ай да юк,
Монда торып файда юк.
Әтисе сүзен тотмый,
Аулакта качып йоклый.

Иртән өенә кайтып
Сөйли башлый шаккатып:
— Төн буена сакладым,
Сыңар керфек какмадым.
Авыр, ахры, кулыбыз,
Тишелми һич солыбыз.

Аптырашып калалар,
Елашып та алалар.
— Инде нишләрбез,— диләр.
Ачка үләрбез,— диләр.
Өметебез аз калды,
Ышаныч шул Таз калды.

— Таз, бүген син барасың,
Борчак чүпләп аргансың,
Мич башыннан төш, әйдә,
Җир сакларга көш, әйдә.
Баргач йоклама ятып,
Иртән сөйләрсең кайтып!

Таз карыша: — Тормыйм,— ди,
Киемем юк, бармыйм,— ди.
Бер аякта чабата,
Берсендә киез ката.
Киреләнмәсен ничек?
Өстә ертык та тишек.

Риза була барырга.
Тик кулга ни алырга?

Бер корык кирәк булыр,
Шул да бик җитеп торыр.
Әгәр дә карак килсә,
Шул корык белән орыр.

Тәвәккәлләп китә ул,
Тиз үк барып җитә ул.
Күтә ызанга ятып,
Әкрен үтә лә вакыт.
Түзеп булмый лабаса,
Күзләрне йокы баса.

Йоклап китәм дигәндә
Көчле давыл кузгала.
Җир өстендә котыра
Әйтерсең лә дәү тырма.
Әй туфракны туздыра!
Шайтаннан да уздыра!

Башта Таз шүрләп кала,
Аннан корыгын ала.
Качкан җирдән чыга да,
Ни булса шул булыр дип,
Корык белән суга да,
Аягыннан ега да.

Озын чәчле бер хатын
Пәйда була шул заман.
Таз кыйный, ул кычкыра,
Ә тавышы бик яман.

Тезләнә Таз алдына:
«Кыйнама!» — дип ялына.

— Типмә минем артыма,
Риза бөтен шартыңа.
Бернинди киртә булмас
Синең тормыш юлыңда.
Иртән кояш чыгуга
Үсеп җитәр солың да.

Кыю икәнсең үзең,
Яхшылап тыңла сүзем:
Мә сиңа чәч бөртегем,
Гел яныңда йөртерсең,
Әгәр кирәгем чыкса,
Шул чәчкә ут төртерсең.

Бөтен эшең уң булыр,
Ни теләсәң шул булыр.

Таз чәч бөртеген алып,
Корыгын иңгә салып,
Иртән өенә кайта,
Урнына менеп ята.
Тазга баш төртү җитә,
Ятуга йоклап китә.

Иртә белән торсалар,
Аптырыйлар барсы да.
Ни арада бу кайткан?

Йоклап ята Таз шайтан!
Кырга барып йөрмәгән,
Качып кайткан, шүрләгән.

Уяталар төрткәләп,
Уклау белән «иркәләп».
Таз әйтә: — Җыеныгыз,
Өлгерде безнең солы.
— Алдыйсың син, Таз пәри!
— Юк, чын сөйлим бу юлы.

Агалары ышанмый,
Сүзе чынга охшамый.
— Шаштың мәллә, дивана,
Бер төн үткән арада
Ничек үссен ди солы,
Алдыйсың, алла колы!

Ышанмыйча баралар,
Хәйран булып калалар —
Сабагы камыш буе,
Урак тыккысыз куе,
Мондый уңыш ул сирәк,
Тизрәк урырга кирәк!

Иртән иртүк барсы да
Җыелып китәләр кырга.
Уралар тирләп-пешеп,
Эшлиләр сөенешеп.
Бетереп кич соң гына,
Кайталар тып-тын гына.

Өч көн буе бәбкәдә
Җиләтәләр киптереп.
Дүртенче көн сугалар
Бөтен шартын китереп.
Көн артыннан көн үтә,
Тарттырыр көн дә җитә.

Алтынчы көн дигәндә
Илтәләр тегермәнгә.
Көнозын чират торып
Апкайталар тарттырып,
Мамык кебек йомшак он,
Әйтү түгел арттырып.

Бер атна үтеп киткәч,
Җомга көн килеп җиткәч,
Иртән торып, җиңгиләр
Мул табын әзерлиләр.
Таз ята мич башында,
Аны бар дип белмиләр.

Абыйлары сыйланалар,
Күр, ничек кыланалар!
Тамакны ныгыталар,
Ә Тазны оныталар.
Тәмле булгач коймагы,
Беткәне тоелмады.

Коймак беткәч табада,
Чират җитә Тазга да.

Бары бер коймак калган,
Аның да өсте янган.
Таз малайны үз итеп
Җиңгәсе бирә илтеп.

Үпкәләгән таз малай:
— Көлмәгез миннән алай!
Коймакны атып бәргән,
Үксеп елап җибәргән.
— Кадеремне белмиләр,
Ашарга да бирмиләр.

Үз киресенә ката,
Тагын йокларга ята.
Вакыт бик әкрен үтә,
Төн урталары җитә.

Абзарда ялгыз кала,
Кулына чакма ала.
Чакмадан ут алдыра,
Теге чәчне яндыра.
Күк күкри, давыл куба,
Бер яшь тай пәйда була.
Корчаңгы гына үзе,
Ут янып тора күзе,

Гүя яшен чаткысы,
Иярендә камчысы.

Могҗизаны юк димә,
Тай шунда телгә килә:
— Атлан, егет, син миңа,
Мәңгелек дус мин сиңа.
Кызганма, сук уң яктан,
Кан чәчрәсен сул яктан.

Тазның сугуы була,
Дөньяга тузан тула.
Җилдәй очып китәләр,
Өч көн, өч төн очкачтын
Бер шәһәргә җитәләр,
Туктап киңәш итәләр.

Шәһәр читендә бер йорт,
Фәкыйрь генә алачык.
Шунда яшәп ята, ди,
Ялгыз гына бер карчык.
Өйгә барып керәләр,
Зурлап сәлам бирәләр.

Кунак килгәч өенә,
Әби шундый сөенә.
Актык тавыгын суеп,
Кунак итә чәй куеп.
Ашап-эчеп ял иткәч,
Егет сорый кич җиткәч:

— Әби, сезнең патшаны
Акыллы, зирәк, диләр.

Аның атларын карарга
Хезмәтче кирәк, диләр.
Иртәгә барып килче,
Патшадан сорап белче.

Әби патшага барган,
Шушындый җавап алган.
Патша әйткән: — Иртәгә
Килсен хезмәт итәргә.
Егет китә шатланып,
Таена ул атланып

Барып җитә патшага,
Сакчы тора капкада.
Тай шунда телгә килә:
— Мине шушында бәйлә.
Ялланырсың патшага,
Мине сыйдырса гына.

Патшага керә егет,
Шартын җиткерә егет.
Патша риза: — Ярар, — ди,
Әнә минем сарай, ди.
Алты баш ат бар минем,
Эшең шул булыр синең:
Өсләрен чистартырсың,
Вакытында ашатырсың.
Шунда бер бүлмә булыр, —
Бу таең шунда торыр.
Авыр булмас хезмәтең,
Күрсәт миңа хөрмәтең.

Моңа кадәр бу эшкә
Алтау өлгергән көчкә.
Аларның барысын да
Патша чыгара куып,
Таз кала монда торып.
Тай бирә алтын канат
Һәм әйтә Тазга карап:

— Шушы канатың белән
Сыйпа атларны һәркөн.
Ялтырап торыр алар,
Хәйранга калыр һәркем.
Таз ул әйткәнчә эшли,
Тае куанып кешни.

Төн үтә дә таң ата,
Иртән патша шакката —
Ялтырап тора атлар,
Менә дигән юртаклар.
Алты хезмәтче эшен
Ничек үти бер кеше?

Хезмәтчеләр көнлиләр,
Нишләргә дә белмиләр.
Сихерен белик, диләр,
Башын бетерик, диләр,
Хәйлә корабыз, диләр,
Саклап торабыз, диләр.

Ә Тазның күңеле шат,
Абзарында алты ат,
Җылы су, сусыл печән,
Ни кирәк тагын бүтән?
Кереп йоклый. Таң белән
Сыйпый ул канат белән.

Хезмәтчеләр күрәләр,
Тазның серен беләләр,
Түкми-чәчми бу хәлне
Патшага җиткерәләр.
— Ярар,— ди ул.— Барыгыз!
Артыгыздан алдыгыз...

Көн артыннан көн үтә,
Таз әйбәт хезмәт итә.
Ашаталар туйганчы,
Йоклый күңеле булганчы...
Уза бәхетле көннәр,
Килә хәсрәтле төннәр.

Патшага кайгы килә —
Кинәт хатыны үлә.
Патша бик ямансулый,
Зиратта үксеп елый
Кочаклап кабер ташын:
— Нишләрмен ялгыз башым?

Тазны дәшә үзенә:
— Колак салчы сүземә.

Хезмәтчем, мине коткар,
Синдә алтын канат бар,
Зурдан булыр бүләгем,
Үтә шушы теләгем.

Канаты булгач, аның
Алтын кошы да бардыр.
Беләсең, күңелем боек,
Җаныма дөнья тардыр.
Син шул кошны алып кайт,
Алтын читлегемә яп!

— Падишаһым-солтаным,
Хезмәтеңә тәйярмын.
Өзеп берни әйтә алмыйм,
Чыгып уйлап карармын.—
Чыга тае янына,
Ябышып атның ялына,

Кочаклап елый Таен:
— Бетте газиз башкаем.
Алтын кош сорый патша,
Кайтма, ди, аннан башка.
Инде хәзер нишләргә?
Җитми терсәк тешләргә.
Таен кочаклап елый,
Дустыннан киңәш сорый.

Кайгырма син, егетем,
Өзмә бер дә өметең,
Өч көнлек ризык сора,
Калганы бездән тора.
Өч көн үтмәс — кайтырбыз.
Патшаны юатырбыз.

Бар әйткәнне әзерләп,
Чыгып китәләр болар.
Зур бер диңгез буена
Барып җитәләр болар.
Яр буенда зур тирәк,—
Шуңа менәргә кирәк.

Асылынып тора өч җеп,
Берсен кисеп төш, егет.
Яшеленә кагылма,
Зәңгәренә орынма.
Кызылын кисеп алып төш —
Барып чыгар безнең эш.

Ашыкма, ләкин тиз бул.
Кара, буталып куйма,
Кызыл җеп кулга төшсә,
Кош кесәңдә дип уйла.
Егет менә агачка.
Җепне кисеп алгач та

Төшеп, Тайга атлана,
Эш уңганга шатлана.

Күңелендә куаныч,
Патшага зур юаныч.
Кошны тапшыра кайтып,
Тынычлап йоклый ятып.

Көннәр үтә дә үтә,
Патшаның бар да җитә.
Өсте бөтен, тамак тук,
Тик тормышның яме юк.
Ялгыз яши, хатынсыз,
Картая бит вакытсыз.

Өйләнсен иде патша,
Көйләнсен иде патша.

Тирә-якка яучылар
Гел җибәреп торса да,
Бүләкләре алтын-көмеш,
Асылташтан булса да —
Әллә сәгате сукмый,
Әллә насыйбы чыкмый.

Патша ишетә: бер шәһәрдә
Алмас патша бар, диләр,
Камыш буйлы, ай күк йөзле
Җиткән кызы бар, диләр.
Исеме Йолдыз икән,
Тиңсез чибәр кыз икән.

Тазны чакырта патша,
Тагын ялына патша:
— Шул Йолдызны тапсана,
Миңа алып кайтсана.
Тыңла, зинһар, сүземне,
Бүләкләрмен үзеңне.

Нәрсә дисен Таз моңа:
— Тырышырмын, җан фида.
Чыгып кочаклый Таен,
Сыйпый да атның ялын
Сөйли бүген патшаның
Нинди йомыш кушканын.

Тае әйтә: — Борчылма,
Чыгарбыз бер очына.
Бусы әле уены,
Алда булыр дуены.
Патшага син хәзер кер,
Шушы шартларны җиткер.

Бик зур кораб ясатсын,
Диңгез белән барасы.
Унике бүлмә булсын,
Унике сәгать булсын,
Сәгатьләрнең телләре
Гел уникедә торсын.

Тып-тын булсын бүлмәсе —
Корабның йөргән тавышы

Ишетелә күрмәсен.
Җиде көнлек юл булыр,
Җиде көннән кайтмасак,
Әҗәлебез шул булыр.

Кушканны үти патша,
Чара юк шуннан башка.
Юлга чыгып китәләр.
Дүртенче көн дигәндә,
Кояш чыгып килгәндә,
Бер атауга җитәләр.

Ярда матур йорт тора.
Егет бер хәйлә кора,
Нишләргә дип баш вата,
Сызылып матур таң ата.
Ә шул йортның чарлагында
Җиде кыз йоклап ята.

Иртән тынлыкны бозып
Кораб кычкырта сузып.
Кызларның иң кечесе
Шул тавышка уяна.
Тутасын да уята,
Шыпырт кына сүз ката:

— Ярда ни ул туктаган,
Әллә юлны бутаган?
Рөхсәт итче, тутием,
Белеп кенә мениием.

— Бар, тик онытылып калма,
Безне борчуга салма.

Төшсә: бик матур кораб,
Кыз тора хәйран карап.
Ишекләр ачык тора,
Бер егет шунда тора.
— Мөмкинме, абый, керергә,
Бераз карап йөрергә?

— Рәхим генә итегез,
Менә монда үтегез.
Кыз түргә таба үтә,
Кораб кузгалып китә.
Кояш каршы, җил уңай,
Кайтып баралар шулай.

Кыз исә берни сизми,
Бүлмәләр карап йөри.
Стенада сәгатьләр
Уникене күрсәтә.
Кыз тынычланып кала,
Ә кораб һаман бара.

Бераздан күзе төшсә —
Сәгать унике һаман!
— Үтте бит күпме заман!
Ай-һай, эшләр бик яман!
Абый, харап иттегез,
Кая алып киттегез?

— Борчылмачы, сеңелем,
Боекмасын күңелең.
Патшабызга кәләш итеп
Алып кайтабыз зурлап.
Патшабикә булып кына
Яшә тормышын нурлап.

Җиде диңгез кичәләр,
Болар кайтып җитәләр.
Музыкалар уйнатып
Шаулатып туй итәләр.
Матур тормыш коралар,
Әйбәт, тату торалар.

Көн артыннан көн үтә,
Таз тыныч гомер итә.
Тик патшаның хатыны
Туганнарын сагына,
Күзе кайту ягында.
Егеткә ачу саклый,
Бәйләнер сәбәп тапмый.

Әйтә берсөн патшага:
— Бу егет,— ди,— бик хәтәр,
Әгәр һәлак итмәсәк,
Башыбызга ул җитәр.
Берәр чарасын карыйк,
Котылу җаен табыйк.

Әтиемнең атлары
Тугайда йөри утлап,
Сиксән баш булыр алар,
Әгәр карасаң чутлап.
Кырык айгыр, кырык бия
Бергә тоталар туплап.

Абзарга керми һичкем,
Яман усаллар алар,
Алларына печәнне дә
Койма аша салалар.
Кем керсә йөрәк җитеп,
Үтерәләр, ди, тибеп.

Кырык айгырдан аерып
Кырык баш биябезне
Таз алып кайтсын монда,
Шуңа хуп диясезме?
Падиша риза булган,
Тазны чакыртып алган:

— Тагын бер үтенеч чыкты,
Хәтердән төшеп калган.
Үтәсәң шул теләгем,
Йөртмәм сине тилмертеп:
Йорт салдырам, өйләндерәм,
Яшәрсең җир җимертеп.

Таз ни әйтсен, бичара,
Баш тартырга юк чара.

Чыга Тае янына,
Сөйләп бирә барсын да:
— Ни кылсам да, һаман аз
Комсыз патша каршында.

Тае әйтә: — Каушама,
Бар, кер дә әйт патшаңа.
Онытма, исеңдә тот,—
Һәрберсе җитмешәр пот
Дүрт аякка дүрт дага
Әзерләтсен, әйт аңа.

Муенга тимер чылбыр,
Җитмеш пот таман булыр.
Тирә-яктан алтын куллы
Осталар тапсын патша,
Вәгъдәсеннән кайтмаска
Шартнамә язсын патша:

«Атларны алып кайтсаң,
Әйткән сүземнән кайтмам».
— Хәзер бар, кер, әйт аңа,
Безнең вакыт әз кала,
Осталарын чакыртсын,
Ә мин йоклыйм, вакыт соң.

Һәр җиргә фәрман китә:
— Тимерчеләр җыелсын!
Җитмешәр потлы чылбыр
Һәм дүрт дага коелсын!

Эш башлауга ай тула,
Кушканнар әзер була.

Иртән кояш чыгуга,
Чыгып китәләр юлга.
Болар чабып үткәндә
Тәрәзәләр уала.
Давыл куба, яшен чатный,
Алар күздән югала.

Өч көн үтте дигәндә,
Кояш чыгып килгәндә,
Килеп җитәләр, агай:
Тимер ишекле сарай,
Чуен белән сипләнгән,
Тимер ишек бикләнгән.

Тай әйтә: — Әнә тирәк,
Шунда мен син тизрәк.
Мин бераздан чыгармын,
Ни булса да чыдармын.
Уң ягымнан кан чыкса,
Кан җиргә тамып торса,
Төшәрсең минем янга,
Бәхилләшербез шунда.

Таз менеп китә өскә.
Тай, йөгереп бөтен көчкә,
Ишеккә китереп тибә,
Ишек ярылып китә.

Икенче кат типкәчтен,
Тупсасыннан каерылып,
Ишек төшә аерылып.

Тай барып керә эчкә,
Мәхшәр башлана эчтә.
Корчаңгы тай сарайны
Өермә күк бөтерә,
Җитмеш потлы дагасы
Типкән саен үтерә.

Бер сәгать үтеп китә,
Ял алыр вакыт җитә.
Тай капкадан чыгуга,
Таз карый уң ягына.
Кан чыкмаган. Шатлыктан
Егыла агач башыннан.

Кире үрмәләп менә.
Тай тагын бәреп керә,
Таз өстән барын күрә —
Тагын сугыша башлый.
Кырык баш айгырның ул
Барысын кырып ташлый.

Кырык бияне каулап
Алып чыгалар юлга.
Тизрәк моннан китәргә,
Өйгә кайтып җитәргә.
Юлда вакыт тиз үтә,
Болар кайтып та җитә.

Аптырый патшабикә.
Патшаның исе китә:
— Ничек алып кайткан бу?
Адәм түгел, шайтан бу.
Теләкләрен үтәрләр,
Безнең башка җитәрләр.

— Патша, Тазны тизрәк
Дөмектерергә кирәк.
— Ничек итеп? Хәйлә тап!
Син бер зур казан ясат,
Кырык чиләк су сыйсын,
Ишегалдында булсын,
Су шаулап кайнап торсын.

Шунда мин ялгыш кына
Төшерермен балдагым,
Төшендеңме калганын?
Таз шуны алып чыгар.
Кайнап торган казанда
Пешмичә ничек чыдар?!

Үтәлмәс ниятләре,
Таралыр сөякләре.
— Булды бу,— ди падиша,—
Акыллы син һәмишә.
Тазны чакыртып ала,
Эшне аңлатып сала.

— Ярый, патшам, баш өсте,
Хушлашыйм Таем белән,
Әзерләт казаныңны,—
Килермен җаем белән.
Кочаклап елый Таен:
— Һәлак булды башкаем,
Их, Тайкаем, нишлибез?
Харап безнең эшебез.

— Кайгырма,—ди, Тай әйтә,—
Котылырбыз ничек тә.
Сүзләремә колак сал,
Хәтереңә уеп кал.

Тамаша кызык булсын,
Бөтен халык җыелсын.
Тик ашыкма төшергә,
Кирәк түгел пешәргә,
Кирәкми ашыгырга
Мондый хәтәр эшләрдә.

Миңа менеп атлангач,
Өч кат әйләнеп чыгам.
Мин өч тапкыр әйләнгәнче
Сикермә, түз: бул чыдам.
Менә шунда теләккә
Ирешербез без, туган.

Өченче кат әйләнгәч,
Мин пошкырып җибәргәч,

Сикер, һич икеләнмә,
Су суынган, шикләнмә.
Балдакны табып чык син,
Авызга кабып чык син.

Шуннан менә белерсең,
Ни булганын күрерсең...

Тамашаны карарга
Бөтен халык җыела,
Арадагы шартнамәгә
Патша мөһере куела:
«Балдакны алып чыкса,
Туй ясыйм, өйләндерәм,
Хәтта патшалыгымнан
Бер өлеш бүлеп бирәм».

Авазбай сөрән сала:
— Тамашабыз башлана!!!

Таз, атланып Таена,
Кузгала үз җаена.
Казан дулап, пар бөркеп
Уртада кайнап тора.
Тай һәр әйләнгән саен
Башын чайкап пошкыра.

Өченче кат пошкыргач,
Таз сикерә казанга.
Халык шаулый, «аһ» итә,

— Ай, һәлак булды бит, ә?!
Таз килеп чыга судан,
Чибәрләнгән, тазарган.

Авызында балдагы.
Патша тагын алдады —
Вәгъдәсеннән баш тарта,
Кирелеге дә арта:
— Мин үзем дә бик чыдам,
Балдакны алып чыгам!

Бик зур учак ягыгыз,
Казанны кайнатыгыз!!!
Кырык чиләкле казан
Буланып кайнап тора.
Хатыны: «Сикермә!» — дип,
Юмалап, җайлап тора.

Тыңламый аны патша,
Атлана юртак атка,
Выжлатып чабып китә.
Күз ачып, күз йомганчы
Өч кат әйләнеп үтә.
Халык тын алмый көтә.

— Булды! — ди патша шунда,
Ярсып сикерә суга.
Явызлыктан шашынып
Ашкына йөрәккәе,

Казанга төшеп җитми —
Тарала сөякләре.

Халык шаулый: — Ах, үлде!
Безгә якты көн килде!
Куаналар, шаулыйлар,
Хәзер безнең егетне
Патша итеп сайлыйлар:
— Гадел патша бул! — диләр.

Бер чибәр кызны сорап,
Туен ясыйлар зурлап.
Биш көн уен итәләр,
Ун көн туен итәләр.
Кәеф-сафа кичәләр,
Чүмеч белән эчәләр
Хуш исле ачы балны,
Миңа... тик сабы калды.

Издание для детей и юношества

Залялов Халим

# ПАРШИВЫЙ ЖЕРЕБЕЦ И ШЕЛУДИВЫЙ МАЛЬЧИК

(на татарском языке)

ИБ № 6459

Редакторы *Ф. Зыятдинова.* Художество редакторы *А. Тимергалина.* Техник редакторы *М. Абитова.* Корректоры *Э. Даутова.* Җыярга тапшырылды 14.05.93. Басарга кул куелды 14.12.93. Форматы 60×90 1/16. Типогр. кәгазе № 2. «Академическая» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 4,50. Нәшер-хисап табагы 1,37. Тиражы 25 000 экз. Заказ П-132. Бәясе ирекле. Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан. Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана 19. Татарстан республикасы Информация һәм матбугат министрлыгының К. Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе типографиясе. 420111. Казан. Бауман ур., 19.